Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 29 июле 63№

Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Әлки муниципаль районы» берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау турында» гы 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карары белән расланган «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Әлки муниципаль районы» берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәнең (2020.05.06, 313№, 2015.18.12, 22№ редак.) 7 пунктының «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«в) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә

һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2.Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин